Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**20.11.2018 ел** **№112**

**Сарман муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге бюджеты турында" карар проектын кабул итү хакында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендәҗирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында" карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Сарман муниципаль районының "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карап тикшерү буенча киләсе составта эшче төркем төзергә:

1) Нургалиев Р. М. – төркем җитәкчесе;

2) Галләмов И. Ф.-төркем әгъзасы;

3) Кошкина Г. А.-төркем әгъзасы;

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеменә ТР, Сарман районы, Җәлил ш.б., Әхмәдиев ур., 26 й., Тел. (85559) 31097 күрсәтелгән язма рәвештә җибәрелә дип билгеләргә.

5. Сарман муниципаль районының 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы «муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында 2018 елның 4 декабрендә 11.00 сәгатькә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы карарына 2018 елның 11 декабренә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны махсус мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә. Кәримов